**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Җөлби торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“19” ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Җөлби торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Җөлби авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Җөлби авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларнын гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш хәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Җөлби авылының Үзәк һәм Киров урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

2) Чишмәне төзекләндерү (төзелеш материалларын сатып алу,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләргә түләү )

3. 2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән чишмәне төзекләндерү өчен 6000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымы кулланылмаган акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :

1) буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Җөлби авылында яшәүче халык җыененың әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Җөлби авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.